**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең**
**Яңа Элмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**№ 3** **16.10.2025 ел**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 16 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыеннары беркетмәләре төзелде:

1. 2026 елда муниципаль районның Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Яңа Элмәле торак пунктында; мотоблок сатып алу, мотоблок өчен асма һәм тагылма җайланмалар сатып алу; триммерлар, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү; трактор өчен ягулык-майлау материаллары, асма һәм тагылма җайланмалар һәм запас частьләр сатып алу; агач кисү, хезмәт хакы түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен махсус техника яллау; генераторлар сатып алу;)

- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Яңа Элмәле торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Яңа Элмәле торак пунктында вак таш сатып алу, урам-юл челтәрен салу һәм чокырларны ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

**- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү** (бункерлар сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 390 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 205 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында 205 катнашучы тавыш бирде; «ЮК» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

**Халык җыены карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча:

2.1. 2026 елда муниципаль районның Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Яңа Элмәле торак пунктында; мотоблок сатып алу, мотоблок өчен асма һәм тагылма җайланмалар сатып алу; триммерлар, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү; трактор өчен ягулык-майлау материаллары, асма һәм тагылма җайланмалар һәм запас частьләр сатып алу; агач кисү, хезмәт хакы түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен махсус техника яллау; генераторлар сатып алу;)

- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Яңа Элмәле торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Яңа Элмәле торак пунктында вак таш сатып алу, урам-юл челтәрен салу һәм чокырларны ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

- **каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү** (бункерлар сатып алу) – **кабул ителгән дип танырга.**

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Яңа Элмәле авылы, Ключевая урамы, 15. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы** **И.М. Җамалтдинов**